ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Советская, д.10, с.Новый Кинер, Арский муниципальный район, 422031

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы, Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 ел, « 01 » апрель** **№ 51**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы Федераль Закон, 2007 елның 18 маендагы 196 нчы номерлы «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында»гы Федераль Законны тормышка ашыру буенча чаралар турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 нче номерлы «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында»гы Россия Федерациясе карары нигезендә Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 1 нче Кушымта һәм 2 нче Кушымта буенча Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 2019 елның 10 мартыннан 5946 сум 47 тиен дип билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кенәр авыл
җирлеге башлыгы Фәхретдинов Р. Ә.

Арча муниципаль районы
Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма
комитетының 2019 елның «01»
апрелендә кабул ителгән 51номерлы
Карарына 1 нче Кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе** *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәк булган документлар рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка предметлар бирү һәм китерү | 3937-43 |
| 3. Мәетне (калдыкларын) зиратка алып бару | 475-51 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1533-53 |
| **Барысы** | **5946-47** |

Арча муниципаль районы
Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма
комитетының 2019 елның «01»
апрелендә кабул ителгән 51номерлы
Карарына 2 нче Кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе** ***(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәк булган документлар рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне төрү | 213-97 |
| 3. Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка предметларны китерү | 3723-46 |
| 4. Мәетне (калдыкларын) зиратка алып бару | 475-52 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1533-52 |
| **Барысы** | **5946-47** |